# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

«16» 11 2021 № 4154

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 елның 26 июлендәге 645 номерлы карары нигезендә

## КАРАР БИРӘ:

1. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 6 сентябрендәге «Тукай муниципаль районы муниципаль мәгариф учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 4049 номерлы карарына үзгәрешләр кертергә:

әлеге карар белән расланган Тукай муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү шартлары турында нигезләмәдә:

VI бүлекнең 14.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14.3. Гомуми белем бирү оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру һәм «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы белән билгеләнгән максатчан күрсәткечләрнең ирешелгән дәрәҗәсен саклап калу максатында, педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә төп эш урыны һәм төп вазыйфасы буенча бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру түләве бирелергә мөмкин.»;

IX бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IX. Гомуми белем бирү оешмасының хезмәткә түләү фондын формалаштыру һәм куллану тәртибе

1. Гомуми белем бирү оешмасының хезмәткә түләү фондын формалаштыру агымдагы финанс елына гомуми белем бирү оешмасының нормативларга, күрсәтелә торган хезмәтләр санына туры китереп билгеләнә торган средстволары күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм гомуми белем бирү оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагыла.

2. Әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән вазыйфаи окладларны, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрне исәпләүләр гомуми белем бирү оешмасы хезмәткәрләренә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре

хезмәткәрләрен, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфаларын да кертеп ) агымдагы финанс елына гомуми белем бирү оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында каралган средстволар хисабына гамәлгә ашырыла.

3. Гомуми белем бирү оешмаларының тиешле чорга (ай, квартал, ел) финанс ягыннан тәэмин итүнең барлык чыганакларыннан, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында барлыкка килгән хезмәткә түләү фондын экономияләү, гомуми белем бирү оешмасының әлеге Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру түләүләренә юнәлдерелергә мөмкин.

Хезмәткә түләү фондын экономияләгәндә кызыксындыру түләүләре хезмәткә түләү фонды экономиясе барлыкка килгән вазыйфаларның һөнәри-квалификация төркеме хезмәткәрләренә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфаларын да кертеп) бирелә.

Гомуми белем бирү оешмасының хезмәт нормасын (хезмәт вазыйфаларын) үтәгән хезмәткәренә тиешле чор өчен хезмәт фондын экономияләү хисабына кызыксындыру түләве, бу чорда эш вакыты нормасын (хезмәт вазыйфаларын) исәпкә алып, агымдагы елның 1 гыйнварена 2000 елның 19 июнендәге «Хезмәткә түләүнең минималь күләме турында» 82-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән хезмәткә түләүнең өч минималь күләменнән артмаска тиеш (педагогик хезмәткәрләр, гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркемнәрен биләгән хезмәткәрләрдән тыш).

Гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесенә хезмәткә түләү фондын экономияләү хисабына кызыксындыру түләве гомуми белем бирү оешмасын гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Гомуми белем бирү оешмаларының финанс ягыннан тәэмин итүнең барлык чыганакларыннан, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында барлыкка килгән хезмәткә түләү фондын экономияләүне файдалану гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесенә йөкләнә.»;

әлеге карар белән расланган Тукай муниципаль районы мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү шартлары турында нигезләмәдә:

V бүлекнең 13.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13.3. Мәктәпкәчә белем бирү оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру һәм «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы белән билгеләнгән максатчан күрсәткечләрнең ирешелгән дәрәҗәсен саклап калу максатында, педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә төп эш урыны һәм төп вазыйфасы буенча бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру түләве бирелергә мөмкин.»;

VIII бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

## «VIII. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының хезмәткә түләү фондын формалаштыру һәм куллану тәртибе

1. Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының хезмәткә түләү фондын формалаштыру агымдагы финанс елына мәктәпкәчә белем бирү оешмасының нормативларга, күрсәтелә торган хезмәтләр санына туры китереп билгеләнә торган средстволары күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм мәктәпкәчә белем бирү оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагыла.

2. Әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән вазыйфаи окладларны, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрне исәпләүләр гомуми белем бирү оешмасы хезмәткәрләренә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфаларын да кертеп) агымдагы финанс елына мәктәпкәчә белем бирү оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында каралган средстволар хисабына гамәлгә ашырыла.

3. Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының тиешле чорга (ай, квартал, ел) финанс ягыннан тәэмин итүнең барлык чыганакларыннан, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында барлыкка килгән хезмәткә түләү фондын экономияләү, мәктәпкәчә белем бирү оешмасының әлеге Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру түләүләренә юнәлдерелергә мөмкин.

Хезмәткә түләү фондын экономияләгәндә кызыксындыру түләүләре хезмәткә түләү фонды экономиясе барлыкка килгән вазыйфаларның һөнәри-квалификация төркеме хезмәткәрләренә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфаларын да кертеп) бирелә.

Мәктәпкәчә белем бирү оешмасының хезмәт нормасын (хезмәт вазыйфаларын) үтәгән хезмәткәренә тиешле чор өчен хезмәт фондын экономияләү хисабына кызыксындыру түләве, бу чорда эш вакыты нормасын (хезмәт вазыйфаларын) исәпкә алып, агымдагы елның 1 гыйнварына 2000 елның 19 июнендәге «Хезмәткә түләүнең минималь күләме турында» 82-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән хезмәткә түләүнең өч минималь күләменнән артмаска тиеш (педагогик хезмәткәрләр, гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркемнәрен биләгән хезмәткәрләрдән тыш).

Мәктәпкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесенә хезмәткә түләү фондын экономияләү хисабына кызыксындыру түләве мәктәпкәчә белем бирү оешмасын гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Мәктәпкәчә белем бирү оешмаларының финанс ягыннан тәэмин итүнең барлык чыганакларыннан, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында барлыкка килгән

хезмәткә түләү фондын экономияләүне файдалану мәктәкәчә белем бирү оешмасы җитәкчесенә йөкләнә.»;

әлеге карар белән расланган Тукай муниципаль районы өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтләренә түләү шартлары турында нигезләмәдә:

VI бүлекнең 6.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6.3. Өстәмә белем бирү оешмалары хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген арттыру һәм «Дәүләт социаль сәясәтен гамәлгә ашыру чаралары турында» 2012 елның 7 маендагы 597 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указы белән билгеләнгән максатчан күрсәткечләрнең ирешелгән дәрәҗәсен саклап калу максатында, педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә төп эш урыны һәм төп вазыйфасы буенча бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру түләве бирелергә мөмкин.»;

IX бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IX. Өстәмә белем бирү оешмасының хезмәткә түләү фондын формалаштыру һәм куллану тәртибе

1. Өстәмә белем бирү оешмасының хезмәткә түләү фондын формалаштыру агымдагы финанс елына өстәмә белем бирү оешмасының финанс чыгымнары нормативларына, кулланучылар һәм күрсәтелә торган хезмәтләр санына туры китереп билгеләнә торган средстволары күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм өстәмә белем бирү оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагыла.

2. Әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән вазыйфаи окладларны, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрне исәпләүләр өстәмә белем бирү оешмасы хезмәткәрләренә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфаларын да кертеп ) агымдагы финанс елына хезмәткә түләүгә өстәмә белем бирү оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында каралган средстволар хисабына гамәлгә ашырыла.

3. Өстәмә белем бирү оешмаларының тиешле чорга (ай, квартал, ел) финанс ягыннан тәэмин итүнең барлык чыганакларыннан, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында барлыкка килгән хезмәткә түләү фондын экономияләү, өстәмә белем бирү оешмасының әлеге Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру түләүләренә юнәлдерелергә мөмкин.

Хезмәткә түләү фондын экономияләгәндә кызыксындыру түләүләре хезмәткә түләү фонды экономиясе барлыкка килгән вазыйфаларның һөнәри-квалификация төркеме хезмәткәрләренә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфаларын да кертеп) бирелә.

Өстәмә белем бирү оешмасының хезмәт нормасын (хезмәт вазыйфаларын) үтәгән хезмәткәренә тиешле чор өчен хезмәт фондын экономияләү хисабына кызыксындыру түләве, бу чорда эш вакыты нормасын (хезмәт вазыйфаларын) исәпкә алып, агымдагы елның 1 гыйнварена 2000 елның 19 июнендәге «Хезмәткә

түләүнең минималь күләме турында» 82-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән хезмәткә түләүнең өч минималь күләменнән артмаска тиеш (педагогик хезмәткәрләр, гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркемнәрен биләгән хезмәткәрләрдән тыш).

Өстәмә белем бирү оешмасы җитәкчесенә хезмәткә түләү фондын экономияләү хисабына кызыксындыру түләве өстәмә белем бирү оешмасын гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Өстәмә белем бирү оешмаларының финанс ягыннан тәэмин итүнең барлык чыганакларыннан, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында барлыкка килгән хезмәткә түләү фондын экономияләүне файдалану өстәмә белем бирү оешмасы җитәкчесенә йөкләнә.»;

2. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 28 августындагы 3889 номерлы карары белән расланган «Тукай муниципаль районы яшүсмерләр клубы» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

I бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 5 пунктны өстәргә:

«5. Тукай муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары җитәкчеләре:

белемнәре һәм эш стажы (эш белгечлеге буенча, билгеле бер вазыйфада) турында документларны һәм хезмәткәрнең вазыйфаи окладлары билгеләнә торган башка нигезләрне тикшерәләр;

ел саен Тукай муниципаль районының яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең тарификация исемлекләрен төзиләр һәм раслыйлар;

Тукай муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын вакытында һәм дөрес итеп билгеләү өчен җаваплылыкка ия»;

IX бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IX. Яшьләр сәясәте оешмаларында хезмәткә түләү фондын формалаштыру һәм куллану тәртибе

1. Яшьләр сәясәте оешмаларында хезмәткә түләү фондын формалаштыру агымдагы финанс елына яшьләр сәясәте оешмаларының финанс чыгымнары нормативларына, кулланучылар һәм күрсәтелә торган хезмәтләр санына туры китереп билгеләнә торган средстволары күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм яшьләр сәясәте оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында яки бюджет сметасында чагыла.

2. Әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән вазыйфаи окладларны, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрне исәпләүләр Тукай муниципаль районының яшьләр сәясәте оешмалары хезмәткәрләренә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфаларын да кертеп) агымдагы финанс елына хезмәткә түләүгә Тукай муниципаль районының яшьләр сәясәте оешмаларының

финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында яки бюджет сметасында каралган средстволар хисабына гамәлгә ашырыла.

3. 3. Яшьләр сәясәте оешмаларының тиешле чорга (ай, квартал, ел) финанс ягыннан тәэмин итүнең барлык чыганакларыннан, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында барлыкка килгән хезмәткә түләү фондын экономияләү, яшьләр сәясәте оешмаларының әлеге Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру түләүләренә юнәлдерелергә мөмкин.

Хезмәткә түләү фондын экономияләгәндә кызыксындыру түләүләре хезмәткә түләү фонды экономиясе барлыкка килгән вазыйфаларның һөнәри-квалификация төркеме хезмәткәрләренә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфаларын да кертеп) бирелә.

Яшьләр сәясәте оешмаларының хезмәт нормасын (хезмәт вазыйфаларын) үтәгән хезмәткәренә тиешле чор өчен хезмәт фондын экономияләү хисабына кызыксындыру түләве, бу чорда эш вакыты нормасын (хезмәт вазыйфаларын) исәпкә алып, агымдагы елның 1 гыйнварена 2000 елның 19 июнендәге «Хезмәткә түләүнең минималь күләме турында» 82-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән хезмәткә түләүнең өч минималь күләменнән артмаска тиеш (педагогик хезмәткәрләр, гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркемнәрен биләгән хезмәткәрләрдән тыш).

Яшьләр сәясәте оешмасы җитәкчесенә хезмәт өчен түләү фондын экономияләү хисабына кызыксындыру түләвенең күләме яшьләр сәясәте оешмасын гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Яшьләр сәясәте оешмаларының  финанс ягыннан тәэмин итүнең барлык чыганакларыннан, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында барлыкка килгән хезмәткә түләү фондын экономияләүне файдалану яшьләр сәясәте оешмасы җитәкчесенә йөкләнә.»;

3. Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының «Тукай муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2020 елның 22 июнендәге 2254 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Тукай муниципаль районында спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында нигезләмәдә:

I бүлеккә түбәндәге эчтәлектәге 5 пунктны өстәргә:

«5. Спорт резервын әзерләү оешмалары җитәкчеләре:

белемнәре һәм эш стажы (эш белгечлеге буенча, билгеле бер вазыйфада) турында документларны һәм хезмәткәрнең  вазыйфаи окладлары билгеләнә торган башка нигезләрне тикшерәләр;

ел саен спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең тарификация исемлекләрен төзиләр һәм раслыйлар;

спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы күләмен үз вакытында һәм дөрес итеп билгеләү өчен җаваплылыкка ия.»;

VI бүлекнең 7.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.3. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 17 октябрендәге 2245-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә спорт резервын әзерләү концепциясен гамәлгә ашыру чаралары планын башкару буенча чаралар планын үтәгәндә, спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренең нәтиҗәлелеген арттыру максатында, педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә һәм икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләргә төп эш урыны һәм төп вазыйфасы буенча бер тапкыр бирелә торган кызыксындыру түләве бирелергә мөмкин.»;

IX бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«IX. Спорт резервын әзерләү оешмаларының хезмәткә түләү фондын формалаштыру һәм куллану тәртибе

1. Спорт резервын әзерләү оешмасының хезмәткә түләү фондын формалаштыру агымдагы финанс елына спорт резервын әзерләү оешмасының финанс чыгымнары нормативларына, кулланучылар һәм күрсәтелә торган хезмәтләр санына туры китереп билгеләнә торган средстволары күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла һәм спорт резервын әзерләү оешмасының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында чагыла.

2. Әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән вазыйфаи окладларны, компенсация һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрне исәпләүләр спорт резервын әзерләү оешмалары хезмәткәрләренә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфаларын да кертеп ) агымдагы финанс елына хезмәткә түләүгә спорт резервын әзерләү оешмаларының финанс-хуҗалык эшчәнлеге планында яки бюджет сметасында каралган средстволар хисабына гамәлгә ашырыла.

3. Спорт резервын әзерләү оешмаларының тиешле чорга (ай, квартал, ел) финанс ягыннан тәэмин итүнең барлык чыганакларыннан, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында барлыкка килгән хезмәткә түләү фондын экономияләү, спорт резервын әзерләү оешмаларының әлеге Нигезләмә нормаларын исәпкә алып кабул ителгән локаль норматив актлары нигезендә кызыксындыру түләүләренә юнәлдерелергә мөмкин.

Хезмәткә түләү фондын экономияләгәндә кызыксындыру түләүләре хезмәткә түләү фонды экономиясе барлыкка килгән вазыйфаларның һөнәри-квалификация төркеме хезмәткәрләренә (эшчеләр, мәдәният, сәнгать һәм кинематография эшчеләренең гомумтармак һөнәрләре һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләрен, җитәкчеләрнең, белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең гомумтармак вазыйфаларын да кертеп) бирелә.

Спорт резервын әзерләү оешмасының хезмәт нормасын (хезмәт вазыйфаларын) үтәгән хезмәткәренә тиешле чор өчен хезмәт фондын экономияләү хисабына кызыксындыру түләве, бу чорда эш вакыты нормасын (хезмәт вазыйфаларын) исәпкә алып, агымдагы елның 1 гыйнварена 2000 елның 19 июнендәге «Хезмәткә түләүнең минималь күләме турында» 82-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән хезмәткә түләүнең өч минималь күләменнән артмаска тиеш (педагогик хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләрдән һәм икенче дәрәҗәдәге физик культура хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри-квалификация төркеменә керүче хезмәткәрләрдән, спорт резервын әзерләү оешмасы җитәкчесеннән тыш).

Спорт резервын әзерләү оешмасы җитәкчесенә хезмәткә түләү фондын экономияләү хисабына кызыксындыру түләве күләме спорт резервын әзерләү оешмасын гамәлгә куючы тарафыннан билгеләнә.

Спорт резервын әзерләү оешмасының финанс ягыннан тәэмин итүнең барлык чыганакларыннан, түләүле хезмәтләр күрсәтүдән алынган керемнәрне дә кертеп, финанс-хуҗалык эшчәнлеге планын үтәү барышында барлыкка килгән хезмәткә түләү фондын экономияләүне файдалану спорт резервын әзерләү оешмасы җитәкчесенә йөкләнә.»;

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә һәм 2021 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

5. «Бюджет һәм казна учреждениеләренә хезмәт күрсәтү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенә әлеге карарны 3 эш көне эчендә районның рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштыруны тәэмин итәргә.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Р. Хәбибуллин